СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.04.2022 г. Агрыз № 17-6

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 15 декабрендәге 13-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Хокук мониторингы нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив-хокукый актны илтеп җиткерү максатларында, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 7 статьясына үзгәреш кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әгерҗе районы прокуратурасының «Муниципаль норматив-хокукый актларга - «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү кирәклеге турында» 2022 елның 06 апрелендәге 02-01-18-2022 номерлы мәгълүматын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 15 декабрендәге 13-3 номерлы карарына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җирле үзидарә буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе

А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
21.04 2022 № 17-6
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 15 декабрендәге 13-3 номерлы карарына ҮЗГӘРЕШЛӘР

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2016 елның 15 декабрендәге 13-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәнең 5 бүлегенең 4 өлешендәге 4 пунктына, аңа «медицина калдыкларын җыю, алардан файдалану, зарарсызландыру, урнаштыру, саклау, транспортировкалау, исәпкә алу һәм утильләштерү» сүзләре белән өстәп, үзгәреш кертергә;».

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2016 елның 15 декабрендәге 13-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәнең 5 бүлегенең 5.1 өлешенә, аңа түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«6) алкогольле, наркотик яисә башка токсик исерек затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру объектлары.».